**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НОВОКИНЕРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
улица Советская, д.10, с.Новый Кинер,
Арский муниципальный район, 422031

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЯҢА КЕНӘР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Совет урамы, 10 нче йорт, Яңа Кенәр авылы,
Арча муниципаль районы, 422031

Тел.,факс (84366)9-12-65, (84366)9-12-68, 9-12-60. E-mail: Nkin.Ars@tatar.ru

# КАРАР

**“09” декабрь 2024 ел** **№ 29**

**Арча муниципаль районы "Яңа Кенәр авыл җирлеге" муниципаль берәмлегендә гражданнардан үзара салым акчаларын җыю тәртибе турында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы "Яңа Кенәр авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге уставы, "Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кенәр авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда (торак пункт территориясенең бер өлешендә) гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында" 2022 елның 04 августындагы 70 номерлы Яңа Кенәр авыл җирлеге Советы карары нигезендә, 12.11.2024 №11, 12.11.2024 №12, 13.11.2024 №13, 13.11.2024 №14, 14.11.2024 №15, 15.11.2024 №16, 18.11.2024 №17, 18.11.2024 №18, 19.11.2024 №19, 19.11.2024 №20 җыеннарда кабул ителгән карарларны гамәлгә ашыру максатыннан, Яңа Кенәр авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Арча муниципаль районы "Яңа Кенәр авыл җирлеге" муниципаль берәмлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын җыю тәртибен расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru/) һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында (http://arsk.tatarstan.ru/) һәм гражданнар күпләп җыела торган урыннарда түбәндәге адреслар буенча мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә: Татарстан Республикасы, Арча районы, Яңа Кенәр авылы, Совет урамы, 10 йорт, Татарстан Республикасы, Арча районы, Сөрде авылы, Совет урамы, 48 йорт, Татарстан Республикасы, Арча районы, Шурабаш авылы, Гагарин урамы, 17А йорт.

3. "Яңа Кенәр авыл җирлеге" муниципаль берәмлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын җыю тәртибе турында" 2023 елның 14 декабрендәге 22 номерлы Яңа Кенәр авыл җирлеге башкарма комитеты карарын үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны өстемә алам.

Яңа Кенәр авыл җирлеге башлыгы Ә.Ә.Гайфуллин

Яңа Кенәр авыл җирлеге
башкарма комитетының
09.12.2024 ел, № 29
карарына кушымта

**Арча муниципаль районы "Яңа Кенәр авыл җирлеге" муниципаль берәмлегендә гражданнардан үзара салым акчаларын җыю тәртибе**

1. Әлеге тәртип Арча муниципаль районы "Яңа Кенәр авыл җирлеге" муниципаль берәмлегендә гражданнардан үзара салым акчаларын җыю кагыйдәләрен билгели.

2. Гражданнарның үзара салым акчаларын Арча муниципаль районы "Яңа Кенәр авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территориясендә теркәлгән 18 яшькә җиткән гражданнар, җыеннарда катнашуларына һәм тавыш биргәндә нинди мөнәсәбәттә булуларына карамастан, 2024 елның 16 февраленә кадәр түлиләр.

3. Гражданнарның түбәндәге категорияләре үзара салым акчаларын түләүдән азат ителә:

а) махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзалары (бергә яшәүче ата-аналар, ир яки хатын, балигъ булган балалар).

4. Гражданнарның аерым категорияләре өчен:

а) 1 нче төркем инвалидлар,

б) 80 яшьтән өлкәнрәк гражданнар,

в) балачактан инвалидлар,

г) хәрби хәрәкәтләр ветераннары,

д) Чернобыль АЭС авариясен бетерүдә катнашучылар,

түләү күләме җирле җыеннар карарында билгеләнгән сумманың 50 (илле) процентын тәшкил итә.

5. Нигезле сәбәпләр булганда:

а) гаилә әгъзасының (ата-анасының, иренең/хатынының, балаларының) вафат булуы,

б) янгын яисә башка табигый бәла-казалар аркасында зыян килү гражданнарга гариза нигезендә түләү кертүне өч айдан да артмаган вакытка кичектерү бирелә.

6. Бер тапкыр түләнә торган түләү турында гражданнарга хәбәр итү бланкы (http://pravo.tatarstan.ru/) бастырып чыгару, Арча муниципаль районының рәсми сайтында (http://arsk.tatarstan.ru/) һәм гражданнар күпләп җыела торган урыннарда мәгълүмат стендларында урнаштыру, шулай ук кул куеп тапшыру яки почта элемтәсе аша җибәрү юлы белән җиткерелә.

Хәбәрнамәдә гражданнарның үзара салым акчаларын күчерүнең түләү реквизитлары, бер тапкыр түләүнең тулы яисә киметелгән күләме, аны түләү срогы булырга тиеш.

7. Гражданнарның үзара салымыннан алынган акчалар Арча муниципаль районы "Яңа Кенәр авыл җирлеге" муниципаль берәмлегенең шәхси счетына керә.

8. Гражданнар тарафыннан түләүләр физик затлар йөкләмәсе буенча исәп-хисап ясарга, почта күчерүләрен башкарырга хокуклы оешмалар (исәп-хисап оешмалары) аша яисә Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша https://uslugi.tatarstan.ru/ сылтамасы буенча акча күчерү юлы белән башкарыла.

9. Түләү фактын приход касса ордеры квитанциясе, чек-ордер, түләү фактын раслый торган башка документлар раслый.

10. Гражданнарның үзара салым акчалары билгеләнгән вакытта кертелмәгәндә, алар законнарда билгеләнгән тәртиптә түләттерелә.

Яңа Кенәр авыл җирлеге
башкарма комитетының
09.12.2024 ел, №29
карарына 2 нче кушымта

**Яңа Кенәр авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге бюджетына үзара салым буенча бер тапкыр түләү турында хәбәрнамә N ______________**

Түләүченең Ф.И.А.и_______________________________________________

Адресы:__________________________________________________________

Нигезе___________________________________________________________

Сезгә ______________________ чараларны гамәлгә ашыруга бер тапкыр түләү_______________________________ суммада ____________ сум түләргә кирәк.

түбәндәге реквизитлар буенча:__________________________________________

алучының банкы БИК _________________________

Сч. N ___________________________________

Алучы Сч. N ____________________________

ИНН _____________________________________

КПП _____________________________________

КБК _______________ОКАТО ______________

Түләүнең билгеләнеше ______________________________________________________

Җитәкче ________________ ______________________________

М. у. (имза) (имзаның аңлатмасы)

- - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - кисем сызыгы - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - -

"Яңа Кенәр авыл җирлеге"муниципаль берәмлегендә бюджетка үзара салым буенча бер тапкыр түләнә торган түләүне түләү турында хәбәрнамә №__
суммада ______________ сум

Түләүченең Ф. и.а.и. _____________________________________________

Адресы: ________________________________________________________

Алдым "___" _____________ 20__ ел ________________________________

(түләүченең имзасы /ФИАи)

Искәрмә: хәбәрнамә түләүчегә шәхсән тапшырылган очракта, өзек тамыр тутырыла һәм Яңа Кенәр авыл җирлеге Башкарма комитетында кала